# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

## КАРАР

№ 248 04.06.2020 ел.

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районында бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында» гы 2013 ел, 25 октябрь,182 нче карарына (Аксубай муниципаль районының 30.07.2014 №215, 17.10.2019 №212, 19.03.2020 №238 карарлары редакциясендә) үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору һәм 2020 елда РФ бюджет системасы бюджетлары үтәлеше үзенчәлекләрен билгеләү турында» 2020 ел, 1 апрель, 103-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Аксубай муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советының 2013 ел, 25 октябрь, 182 нче карары белән расланган Аксубай муниципаль районында бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәгә (Аксубай муниципаль районы Советының 30.07.2014 ел, №215, 17.10.2019 ел, №212, 19.03.2020 ел,№238 карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2021 елның 01 гыйнварына кадәр гамәлдә булуын туктатып тору:

Нигезләмәнең 10 статьясындагы 2 пункты, 26 статьясындагы 1 пункты, 34 статьясындагы 1 пункты, 37 статьясындагы 3 пункты, 38 статьясындагы 1 пункты.

2. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2020 елга һәм 2021, 2022 еллар план чорына Район бюджетын төзегәндә һәм үтәгәндә барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http://Aksubaevo.tatarstan.ru һәм хокукый мәгълүмат порталында бастырырга: http://pravo.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Аксубай муниципаль районы Советының бюджет, салымнар һәм финанс, җыемнар, инвестицияләр һәм эшмәкәрлек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Аксубай муниципаль районы башлыгы,
Совет Рәисе: К. К. Гилманов